**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН АТНИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

“18” гыйнвар 2021 ел № 5

## Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Башлыгының 2020 елның 03 февралендә кабул ителгән «Әтнә районы җирлегендә эшләүче һәм яшәүче аерым категория гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында» 7 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенең, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең, 2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын үтәүнең көтелгән нәтиҗәләре йомгаклары һәм 2021 елга республиканың финанс, казначылык һәм салым органнарының 2020 елның 18 декабрендәге бурычлары буенча уртак коллегиясенең беркетмә йөкләмәсен үтәү максатларында, Әтнә муниципаль районы башлыгы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы башлыгының 2020 елның 03 февралендәге «Әтнә районы җирлегендә эшләүче һәм яшәүче аерым категория гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында» 7 нче номерлы карарына түбәндәге эчтәлектәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 нче пункты яңа редакциядә бәян итәргә:

“ 1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында эшләүче һәм яшәүче мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсе хезмәткәрләренә торак мәйданының Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән социаль нормасы чикләрендә торак, газ, электр белән тәэмин итү өчен түләү чыгымнарының 100 проценты күләмендә социаль ярдәм чараларын һәм коммуналь хезмәтләрдән файдалану нормативларын билгеләргә. Күрсәтелгән социаль ярдәм чарасы шулай ук пенсиягә чыккан авыл җирендә яшәүче һәм авыл җирлегендә урнашкан мәдәният учреждениеләрендә 10 елдан да ким эшләмәгән хезмәткәрләргә дә бирелә”

түбәндәге эчтәлектәге 1.1. пункты белән тулыландырырга:

“1.1. Күрсәтелгән социаль ярдәм чарасын алу шарты булып Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмә бирү тора”

2. Әлеге карарны pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әтнә районы башкарма комитеты җитәкчечәнә йөкләргә.

Район башлыгы Г.Г. Хәкимов